ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге белән чиктәш чикләрен һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге
территориясе чикләре
**карта-схемасы**

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген
төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр
округы статусын бирү турында» Татарстан
Республикасы Законына 1 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге

63 - тоташу ноктасының тәртип саны

«Чаллы шәһәре» муниципаль
берәмлегенең чиктәш чикләре тасвирламасы

63 - / звеносы – Алабуга муниципаль районы
/ - 65-63 звеносы – Тукай муниципаль районы»;

2) 2 нче кушымтаның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ч.б.н. 13-16: урман массивының көньяк-көнбатыш, көньяк-көнчыгыш, көнчыгыш чикләре буйлап, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 60 м, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 60 м, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буйлап М-21 автомобиль юлы киселешенә кадәр;».


**3 статья**

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2012, № 4; 2014, № 12 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

43(62)-44(63) - Алабуга муниципаль районы
44(63)-56 - «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге
56-1(64) - Алабуга муниципаль районы
1(64)-8(66) - Менделеевск муниципаль районы
8(66)-9(67) - Әгерже муниципаль районы
9(67)-21(68) - Минзәлә муниципаль районы
21(68)-26(86) - Сарман муниципаль районы
26(86)-37(87) - Зәй муниципаль районы
37(87)-43(62) - Түбән Кама муниципаль районы

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемада № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Әҗмәкәй авыл җирлеге |
| 2 | Бәтке авыл җирлеге |
| 3 | Биклән авыл җирлеге |
| 4 | Боерган авыл җирлеге |
| 5 | Борды авыл җирлеге |
| 6 | Иштирәк авыл җирлеге |
| 7 | Калмаш авыл җирлеге |
| 8 | Калмия авыл җирлеге |
| 9 | Князево авыл җирлеге |
| 10 | Комсомолец авыл җирлеге |
| 11 | Круглое Поле авыл җирлеге |
| 12 | Күзкәй авыл җирлеге |
| 13 | Күче Шилнә авыл җирлеге |
| 14 | Мәләкәс авыл җирлеге |
| 15 | Мусабай-Завод авыл җирлеге |
| 16 | Түбән Суыксу авыл җирлеге |
| 17 | Яңа Троицкий авыл җирлеге |
| 18 | Сәмәкәй авыл җирлеге |
| 19 | Иске Абдул авыл җирлеге |
| 20 | Иске Дөреш авыл җирлеге |
| 21 | Теләнче-Тамак авыл җирлеге |
| 22 | Шилнәбаш авыл җирлеге |
| 23 | Яңа Бүләк авыл җирлеге |

»;

2) 2 нче кушымтаның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш чиге 56 нчы тоташу ноктасыннан, сынык сызык ясап, Түбән Кама ГЭСының гидротехник корылмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 1,71 км уза, алга таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 380 м көньяк-көнчыгышка, 2,55 км төньяк-көнчыгышка һәм 410 м көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, «Чаллы элеваторы» ачык акционерлык җәмгыятенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 760 м, көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 570 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 580 м уза, алга таба яңадан Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап төньяк-көнбатышка 430 м, Шилнә елгасы тамагына кадәр төньяк-көнчыгышка 10,1 км, әлеге елга агымы буйлап өскә таба 2,0 км бара, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка 220 м, сынык сызык ясап, урман массивының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап көньякка 340 м бара, аннары урман массивы буйлап көньяк-көнчыгышка 90 м, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 140 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 70 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 780 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м, сынык сызык ясап, урман массивының көнбатыш чиге буйлап көньякка 150 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 330 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 220 м, сынык сызык ясап, урман массивы буйлап көньяк-көнчыгышка 470 м, сынык сызык ясап, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 460 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнчыгышка 70 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибә торган инешне узып, төньяк-көнчыгышка 240 м бара, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 90 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнчыгышка 60 м, сынык сызык ясап, көнбатышка 60 м бара, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба гомуми юнәлештә 1,98 км, урман массивы буйлап көньяк-көнчыгышка 80 м, сынык сызык ясап, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,05 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 210 м, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап 80 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка 690 м, автомобиль юлын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньякка 20 м бара, аннары агач-куак үсемлекләр массивы буйлап көньяк-көнчыгышка 70 м, профильле автомобиль юлы буйлап 700 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,36 км көньяк-көнчыгышка, 1,43 км көньяк-көнбатышка, 3,11 км көньяк-көнчыгышка, 350 м төньяк-көнчыгышка, «Чаллы су алу җайланмасы – Ильбухтино – Калмия – «Минзәлә – Боерган» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Шилнә елгасына кадәр яңадан көньяк-көнчыгышка 1,2 км, әлеге елга агымы буйлап өскә таба ул Гәрдәле елгасына кушылганчы 780 м бара, аннары Гәрдәле елгасы агымы буйлап өскә таба 2,01 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 700 м һәм көньяк-көнчыгышка 540 м бара, аннары урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 130 м, авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 160 м, көньяк-көнбатышка 370 м, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 230 м уза, алга таба агач-куак үсемлекләр массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 70 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, агач-куак үсемлекләр массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 70 м, сынык сызык ясап, Ордиушка елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,4 км, көньяк-көнчыгышка 70 м бара, аннары буаның уң яры буйлап төньяк-көнбатышка 150 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 420 м, коллектив бакчаларның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 80 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 350 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 15 м уза, алга таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,11 км Тогай – Шилнәбаш автомобиль юлы белән кисешкәнче, Шилнәбаш елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка бара, аннары Тогай – Шилнәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 430 м, сынык сызык ясап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 2,11 км уза, алга таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап, Камыслы инешен һәм Ордиушка елгасын кисеп үтеп, көнбатышка 660 м, сынык сызык ясап, каты көнкүреш калдыклары полигонының төньяк чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 800 м, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 330 м, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 470 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 730 м бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 670 м уза, алга таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне, Ордиушка елгасын, Камыслы инешен кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 2,09 км уза, Тогай – Шилнәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлы белән кисешкәнче 460 м уза, алга таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Шилнәбаш елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка 2,15 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 1,4 км, төньяк-көнбатышка 250 м, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап 140 м һәм көньяк-көнбатышка 30 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,18 км һәм төньяк-көнбатышка 610 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 620 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка 50 м, питомникның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 280 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 980 м, питомникның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 310 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибә торган инешне кисеп үтеп, 260 м бара, аннары питомникның көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 1,0 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,61 км, коллектив бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 240 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка 50 м, коллектив бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 50 м, көньяк-көнбатышка 50 м, төньяк-көнбатышка 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 220 м, коллектив

бакчаларның төньяк-көнчыгыш чигеннән 190 м, Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаны кисеп чыгып, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 320 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне кисеп чыгып, көньяк-көнчыгышка 720 м, зиратның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 200 м, көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 1,11 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 120 м уза, алга таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,04 км, Ялхов инеше агымы буйлап аска таба ул Чаллы елгасына коя торган җиргә кадәр 1,89 км бара, әлеге елга агымы буйлап өскә таба, Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 5,65 км уза, алга таба агач-куак үсемлекләр массивының көньяк чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 50 м, Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 10 м, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап 20 м бара, әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 380 м, коллектив бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап көньякка 800 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, коллектив бакчалар буйлап көньяк-көнбатышка 320 м, сынык сызык ясап, коллектив бакчаларның көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,27 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка 330 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап төньякка 600 м бара, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап көнбатышка 80 м, көньяк-көнбатышка 130 м, сынык сызык ясап, көньякка 450 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 1,14 км, сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап көнчыгышка 200 м, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап көньяк-көнчыгышка 40 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлларын кисеп үтеп, көньякка 400 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап көнбатышка 2,47 км бара, аннары сәнәгать объектының көнчыгыш чиге буйлап көньякка 180 м, көньяк чиге буйлап көнбатышка 80 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньякка 380 м уза, алга таба Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,68 км, сәнәгать объекты буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 650 м, сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 190 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 930 м бара, аннары Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,19 км, Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 2,88 км, сәнәгать зонасы буйлап төньякка 390 м һәм көньяк-көнчыгышка 90 м уза, алга таба сәнәгать зонасының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 240 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 690 м, сәнәгать зонасы буйлап, сынык сызык ясап, көньякка 650 м бара, сәнәгать зонасының көньяк чиге буйлап көнбатышка 360 м, төньякка 620 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 300 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 280 м уза, алга таба сәнәгать зонасы буйлап көньякка 230 м, көньяк-көнбатышка 150 м бара, сәнәгать зонасының көнбатыш чиге буйлап төньякка 70 м, сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 200 м, Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап

көньяк-көнбатышка 140 м, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка 60 м уза, алга таба профильле автомобиль юлы буйлап, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 90 м төньякка һәм 430 м төньяк-көнбатышка, индустриаль объектның көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 90 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 230 м һәм төньякка 150 м бара, аннары тондыргычның көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, көнбатышка 490 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка 140 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап көньякка һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 220 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 90 м, күл буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнчыгышка 40 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 50 м һәм, сынык сызык ясап, төньякка 130 м, алга таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 240 м, автомобиль базарының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 290 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 30 м бара, аннары Куйбышев тимер юлы тармагына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 1,54 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 60 м, сынык сызык ясап, көнбатышка 810 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 470 м уза, алга таба сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 930 м, көньяк-көнчыгышка 120 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка 30 м һәм төньякка 20 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, казылган кишәрлек буйлап 60 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 60 м, кибә торган инеш агымы буйлап аска таба 40 м, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап төньяк-көнбатышка 20 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м, коллектив бакчаларның төньяк чиге буйлап 190 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,78 км, коллектив бакчаларның көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньякка 590 м, автомобиль юлын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка 10 м бара, агач-куак үсемлекләр массивы буйлап төньяк-көнчыгышка 10 м, Куйбышев сусаклагычының сул яры буйлап, сынык сызык ясап, төньякка 130 м, агач-куак үсемлекләр буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 60 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,61 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 44 нче (63 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов


Казан, Кремль
2019 ел, 27 декабрь
№ 114-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Муниципаль берәмлекләрнең үзгәртүләр исәпкә алынган чикләре

<u>карта-схема</u>




Шартлы билгеләр

- Тукай муниципаль районы һәм «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Тукай муниципаль районы һәм «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелә торган Тукай муниципаль районы һәм аның составындагы Кече Шилнә авыл җирлеге территориясе